# Әдәби телдә алынма сүзләрнең тоткан урыны

Эшне башкарды: Гатина Ә.Р.

Татар әдәби телендә башка телләрдән кергән алынмалар, нигездә, төп ике төргә бүлеп карала:

- Гарәп-фарсы алынмалары;
- Рус теленнән һәм аның аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләр.

# Гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләр

Татар әдәби телендә нормалашкан гарәп-фарсы сүзләрен лексик-семантик яктан берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

- Кешенең холкы, эше, эмоцияләре һәм эчке кичерешләре белән бәйләнешле сүзләр: *хафа, сер, зиһен, инсаф, хис, хәсрәт һ.б.*
- Әдәбият, язучылык эше белән бәйләнешле сүзләр: *әсәр, әдип, әдәбият, тасвир, иҗат, дастан һ.б.*
- Уку-укыту, фән, мәгариф эше белән бәйләнешле сүзләр: *җәдит, имтихан, әлифба, хәреф, имла, дәфтәр һ.б.*

- Иҗтимагый-публицистик эчтәлеккә ия булган сүзләр: *сыйныф, фетнә, канун, мәдәният, милләт, нәфрәт һ.б.*
- Тормыш-көнкүрешкә караган сүзләр: *әсбап, арба, ихата, пәрдә, пыяла, базар һ.б.*
- Кеше, аның тормышы һәм сәламәтлеге белән бәйләнешлә сүзләр: *зат, инсан, адәм, сабый, каһарман, баһадир һ.б.*
- Вакыт, пространство, табигать күренешләре, тереклек белән бәйләнешле сүзләр: *гасыр, вакыт, дәвер, заман, җисем, галәм һ.б.*
- Администрация, идарә, хөкем,сугыш эшләре белән бәйләнешле сүзләр: *идарә, әмир, патша, шаһ, мөһер, җәза һ.б.*

- Аралашуның төрле өлкәләренә караган гомуми абстракт һәм башка сүзләр: *тәбрик, хорафат, сәбәп, шарт, рөхсәт, сәлам һ.б.*
- Дини сүзләр: *әүлия, суфи, мәчет, сират, гает, госел, мөфти, мулла, намаз һ.б.*
- Предметларны ачыклап килүче сыйфатлау сүзләре: *хуш, зирәк, хәтәр, саф, залим, газиз, кабахәт һ.б.*
- Сыйфат һәм рәвеш функциясендә йөри торган сүзләр: *шат, рәхәт, гафил, горур, начар һ.б.*
- Алмашлыклар, ярдәмлекләр, грамматик яктан мәгънә бәйләнешенә катнашмаган сүзләр: *әлбәттә, әмма, хәтта, ифрат һ.б.*
- Ярдәмче фигыльләр белән килә торган сүзләр: әһәмият, хасил, дәвам, тәмам һ.б.

# Көнбатыш Европа һәм рус телләренән кергән алынма лексика

- Кием-салым исемнәре: *перчатка, галуш, эшләпә һ. б.*
- Ашау-эчү, савыт-саба әйберләре һәм шуңа бәйләнешле сүзләр: *тәлинкә, эскәтер, прәннек, кофе h.б.*
- Йортның аерым өлешләре һәм җиһазлар белән бәйләнешле сүзләр: *номер эчендә ике өстәл, бер диван; балкунлап салынган; картина, бер өстәл, бер кровать (Ф.К.)*
- Көндәлек аралашу барышында кулланыла торган тормыш-көнкүреш сүзләре: *Диярләр чүп: саламдыр бу (Г.Ч.); миллион предан; пакет-пакет акча (Ф.Х.).*

- Үлчәү, вакыт берәмлекләрен, ай исемнәрен белдергән сүзләр: *егерме пот ашлык; дисәтинә (Ф. Х); Килограмм (Ш.А.).*
- Профессия һәм хезмәт урыны белән бәйләнешле сүзләр: *почетный граҗданин; горничная; бай приказчигы, хозяйка кызы (Ф.Ә.).*
- Дәүләт, җәмәгать учреждениеләре һәм төрле корылыш белән бәйләнешле сүзләр: *Иске заманда фабрикалар булмаган (З.Б.); Сабын заводы, ресторан, буфет (Ф.Ә.).*
- Музыка өлкәсенә караган сүзләр: *граммофонда татар җырлары(Г.Т.); музыка (Р.Ф.); пианино дәресләре (Ф.Ә.)*

- Әдәбият-журналистика белән бәйле сүзләр: *милли роман (М.А.); Драма (Г.Ил.); Драмнарны сүзләп утырма (Ф.Х.).*
- Банк, финанс, почта эшләре белән бәйләнешле сүзләр: *пакет, посылка, счет (К.Н.).*
- Мәгариф, уку-укыту өлкәсенә караган сүзләр: *семинария шәкертләре; инспектор хәзрәтләре үз файдасына күндерде; үзе классқа килгәч оныта икән; грамматика яздырып бастыруы (К.Н.).*
- Матур әдәбият һәм публицистика стилендә кулланыла торган төрле фәннәр белән бәйләнешле сүзләр: *барометр, термометр, манометр, фотография, литография (К.Н.)*

- Медицина өлкәсенә караган сүзләр: *акушерская, апоплексия сугу (З.Биг.); аспиринныэчтем, докторга ышанам, аркасына массаж өчен (Г.Т.).*
- Транспорт һәм аның белән бәйләнешле сүзләр: *суднолар, баркалар йөри (К.Н.), Билет алу (З.Һ.), файтонга утырып (Ф.Х.).*
- *Төрле өлкәгә караган башка сүзләр: идеалы анда, шул металлның бәндәсе, мәктәпләр- безнең арсенал, ул җирдә унбиш шпион (Г.Т.); участок, приют (Г.Кол.); комплименты ошады, методы шул, сиңа сюрприз, комик (Ф.Ә.).*